БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 2020 г. № _____

**2015 елның 9 июнендәге 264 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында» 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Россия Федерациясе Президентының боерыгы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2015 елның 9 июнендәге 264 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакытта» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның 1 абзацында «хисап чорыннан соң килүче елның 30 июленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары нигезендә

белешмәләр бирелгән көннән алып бер ай эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татартсан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов